**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении показателей, необходимых для мониторинга обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан»**

В целях совершенствования деятельности по мониторингу обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в приложение к Указу Президента Республики Татарстан от 29 июля 2009 года № УП-393 «Об утверждении показателей, необходимых для мониторинга обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 29 февраля 2012 года № УП-159, от 17 марта 2014 года № УП-279, от 14 мая 2016 года № УП-411, от 7 апреля 2018 года № УП-297 и от 29 марта 2019 года № УП-189) следующие изменения:

а) пункт 1.4 изложить в следующей редакции:

«1.4. Доля налоговых деклараций, представленных налогоплательщиками (организациями, индивидуальными предпринимателями и физическими лицами) в электронном виде, в общем количестве представленных налоговых деклараций, процентов»;

б) в пункте 4.3 слово «Управления» заменить словами «Управления Федерального казначейства по Республике Татарстан»;

в) пункт 12.2 изложить в следующей редакции:

«12.2. Сроки совершения таможенных операций, связанных с завершением действия таможенной процедуры таможенного транзита, не более чч:мм:сс, где «чч» – часы, «мм» – минуты, «сс» – секунды»;

г) пункт 12.3 изложить в следующей редакции:

«12.3. Сроки регистрации документов, представленных для помещения товаров на временное хранение, не более чч:мм:сс, где «чч» – часы, «мм» – минуты, «сс» – секунды»;

д) пункт 14 изложить в следующей редакции:

«14. Волжско-Камское межрегиональное управление Федеральной службы по надзору в сфере природопользования».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 марта 2020 года
№ УП-218

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы һәм 2019 елның 29 мартындагы ПУ-189 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Тапшырылган салым декларацияләренең гомуми санында салым түләүчеләр (оешмалар, шәхси эшкуарлар һәм физик затлар) тарафыннан электрон рәвештә тапшырылган салым декларацияләренең өлеше, процентларда»;

б) 4.3 пунктта «Идарә» сүзен «Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 12.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.2. Таможня транзиты таможня процедурасы тәмамлануга бәйле таможня операцияләрен башкару сроклары сс:мм:сс тан артык түгел, биредә «сс» – сәгать, «мм» – минут, «сс» – секунд»;

г) 12.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3. Товарларны вакытлыча саклауга урнаштыру өчен бирелгән документларны теркәү сроклары сс:мм:сс тан артык түгел, биредә «сс» – сәгать, «мм» – минут, «сс» – секунд»;

д) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 30 март
№ ПУ-218